**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1020**
**16.02.2023**

Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 номерлы карары (Башкарма комитетның 2014 елның 17 февралендәге 944 номерлы, 2015 елның 18 ноябрендәге 6571 номерлы, 2016 елның 29 апрелендәге 2159 номерлы, 2017 елның 6 апрелендәге 1955 номерлы, 2018 елның 7 мартындагы 1180 номерлы, 2019 елның 22 октябрендәге 5404 номерлы карарлары редакцисендә) белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 пунктның 3 пунктчасында «Россия Федерациясе Пенсия фондында» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондында» сүзләренә алмаштырырга;

2) 7.1 пунктта:

- 5 пунктчада «Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан (Россия Федерациясе Пенсия фондында)» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

- 6 пунктчада «(Россия Федерациясе Пенсия фонды)» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга;

3) 10.1 пунктта «Россия Федерациясе Пенсия фондында» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондында» сүзләренә алмаштырырга;

4) 14.1 пунктта «Россия Федерациясе Пенсия фондында» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов